СИШӘМБЕ
9
МАРТ
1943 ел.
№ 55 (6777)
Аерым номеры 20 тиен.

ВАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һәм КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Яхшы инициатива

Газетабызның 28 нче февраль номерында Кукмара районының агач әзерләү һәм ташу буенча алдынгы колхозчыларының мөрәҗәгате басылып чыкты. Кукмара районы колхозчыларының республикабыздагы барлык колхозчыларга һәм колхозчы хатын-кызларга мөрәҗәгать итү өчен бөтен нигезләре бар. Алар агач әзерләү буенча районга бирелгән көзге-кышкы сезон заданиесен 25 нче февральгә 71 процентка, ташу буенча—84 процентка үтәгәннәр.

Кукмара районы колхозчылары, агач әзерләү һәм ташу буенча сезон заданиесен үтәүне 15 нче мартка тәгәлләү өчен көрәшеп, республикабыздагы барлык колхозчыларны да үзләреннән үрнәк алырга чакыралар. Алар:

— Без, рсепубликабыздагы барлык колхозчыларга мөрәҗәгать итеп, март аен Дәүләт Оборона Комитеты билгеләгән сезон планын срогыннан алда тәгәлләү ае дип игълан итәргә чакырабыз,—диләр.

Кукмара районы колхозчыларының чакыруы гаять зур политик әһәмияткә ия булып тора. Патриотик хис белән тулган чакыру бу! Үзеңнең ил алдындагы бик зур һәм мактаулы бурычыңны тирәнтен аңлау бу! Агач — ул, төзү материалы. Агач — ул, ягулык. Ә төзү материаллары һәм ягулык исә безнең фронт өчен эшләүче промышленностебызга кирәк, тылыбызда фронт өчен һәм көн-күреш тормыш өчен эшләүче безнең дистәләрчә, йөзләрчә предприятиеләребезгә кирәк. Ә фронт һәм тыл—ул барысы да! Бөтен көч, барлык энергия әнә шуңа, безнең промышленностебызның нормаль эшләве өчен, тылның тормышы нормаль темп белән агуы өчен бирелергә тиеш. Явыз һәм кабахәт дошманга каршы бөек ватан сугышы барган чорда аның әһәмияте аеруча зур. Кукмара колхозчылары әнә шуны аңлап эш итәләр һәм бөтен көчләрен шуңа бирәләр.

Республикабызда үз бурычларын һәм ил алдындагы җаваплылыкларын аеруча яхшы аңлаган колхозлар һәм районнар аз түгел. Мондый колхозлар һәм мондый районнар агач әзерләү һәм ташу эшендә дә яхшы күрсәткечләр бирәләр. Красный бор районы колхозлары агач әзерләүнең сезон заданиесен 25 нче февральгә 72 процентка, ташу буенча—92 процентка, Әгерҗе районы колхозлары шул ук вакытка агач әзерләүне 60 процентка, ташуны 85 процентка, Саба районы колхозлары агач әзерләүне 60 процентка, ташуны 69 процентка үтәгәннәр.

Агач әзерләү һәм аны тиешле урыннарга ташып кую буенча республикабыздагы барлык районнарда да эш уңышлы тора, дип уйлау, әлбәттә, хата булыр иде. Күп кенә районнарда әле эшнең бу бик әһәмиятле тармагына бәя биреп җиткермиләр һәм шуның белән Дәүләт Оборона Комитетының заданиесен вакытында үтәүне өзәләр. Чистай районында (ВКП(б) райкомы секретаре Матвеев, райбашкарма комитеты председателе Саксин) агач әзерләү 16 процентка, ташу—8 процентка, Куйбышев районында (ВКП(б) райкомы секретаре Вахрушев, райбашкарма комитеты председателе Чванов) агач әзерләү 23 процентка, ташу—7 процентка гына үтәлгән. Әлки, Яңа Писмән, Тәмте, Балык бистәсе, Акташ һәм Заинский районнарында бу өлкәдә эш аеруча начар торганлыгын әйтергә кирәк. Болай хурлыклы рәвештә артка калучылыкка чик куелырга тиеш. Бу өлкәдә алда баручы Кукмара һәм башка районнарның колхозларыннан үрнәк алырга, аларның эш тәҗрибәләреннән киң файдаланырга кирәк.

Кукмара районы колхозчыларының патриотик чакыруын республикабызның барлык колхозчылары да эләктереп алырлар һәм агач кисү һәм ташу буенча март аенда бик зур уңышларга ирешерләр. Барлык эшне оештырырга, колхозчылар арасындагы политик һәм производство активлыгына җитәкчелек итәргә генә кирәк.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР СЫЧЕВКА ШӘҺӘРЕН АЛДЫЛАР

8 нче мартта безнең гаскәрләр, ике көнлек каты сугышлардан соң, дошманның каршылык күрсәтүен сындырдылар һәм СЫЧЕВКА шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар. (ВЯЗЬМА шәһәреннән төньяктарак).

Сычевка юнәлешендә һәм Сычевка шәһәре өчен булган сугышларда безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны кулга төшерделәр: самолетлар—8, танклар—310, төрле калибрдагы орудиеләр—40, пулеметлар—250, паровозлар—22, вагоннар һәм тимер юл цистерналары—215, шулай ук күп снарядлар, миналар, патроннар һәм башка хәрби милекләр.

Дошман үтерелгән хәлдә генә дә 8.000 гә якын солдат һәм офицерларын югалтты.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

БӨЕК ПОЛКОВОДЕЦ ИПТӘШ СТАЛИН ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ КЫЗЫЛ АРМИЯ ДОШМАННЫ ТӘМАМ ТАР-МАР ИТӘР

ЧЫН КҮҢЕЛДӘН КОТЛЫЙЛАР

Стахановчы, икейөз процентчы иптәш Бутузов СССР Верховный Советы Президиумының иптәш Сталинга хәрби исем—Советлар Союзы Маршалы исемен бирү турындагы Указын радиодан ишетте. Эшкә килгәч ул бу шатлыклы хәбәрне иптәшләре белән уртаклашырга ашыкты. Беседа стихияле төстә башланды. Эшчеләр бу хәбәрне җанлы рәвештә тикшерделәр. СССР Верховный Советы Президиумының Указын чын күңелдән котладылар.

— Мин бу вакыйга хөрмәтенә,—диде иптәш Бутузов, — тагын да яхшырак эшләргә булдым. Бүгенге көннән башлап мин смена заданиесен 250—300 процентка үтәп барачакмын.

Иптәш Бутузовның фикерен барлык эшчеләр яклап чыктылар.

— Без дә синнән калышмабыз,—диделәр алар.

Мастер иптәш Дундин болай диде:

— Стахановчылар яхшы эшләргә сүз бирәләр. Мин дә, мастер буларак, алардан калышмам. Бүгенге көннән продукция эшләп чыгаруны арттырырга, үз участогымда программадан тыш өстәмә рәвештә бер изделие эшләп чыгарырга өйкләмә алам.

Шулай, Н-че заводның йөзләрчә стахановчылары СССР Верховный Советы Президиумының указын эшлекле рәвештә өйрәнделәр. Кичә һәм бүген цехларда бу турыда беседалар, газета укулар, җыелышлар булып үтте. Партоешма секретаре иптәш Григорьев булган цехта СССР Верховный Советы Президиумы Указына багышланган «Молния» стена газетасы чыкты. Начальнигы иптәш Андреев булган цех коллективы СССР Верховный Советы Президиумының иптәш Сталинга Советлар Союзы Маршалы исемен бирү турындагы Указы хөрмәтенә 15 нче марттан стахановча вахтага басарга һәм 1 нче майны хезмәттә яңа уңышларга ирешү белән каршыларга булды.

ЯШЬ ПАТРИОТЛАР ҖАВАБЫ

СССР Верховный Советы президиумының иптәш Сталинга Советлар Союзы Маршалы дигән исемне бирү турындагы Указын комсомол оешмасы секретаре иптәш Колесников булган завод яшьләре гаять зур производство күтәренкелеге белән каршыладылар.

Яшь стахановчылар үз өсләренә яңа йөкләмәләр алдылар. Комсомолецлардан Вавилов, Волосевич, Валиәхметов һәм башка иптәшләр, моңа кадәр сменага 5 әр норма биреп килсәләр, хәзер тагын да яхшырак эшләргә сүз бирделәр. Уннарча алдынгы яшьләр стахановчылар вахтасына бастылар. Комсомолка Ранеткина нормасын 5 тапкырга арттырып үти башлады. Гришаев, Васягин, Машков, Моисеев, Дурова, Константинов һәм башка иптәшләр көнгә икешәр-өчәр норма бирәләр.

Заводта күп кенә фронт бригадалары төзелде. Бу бригадалар заданиеларын беренче көннән үк арттырып үти башладылар.

КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ БҮЛӘКЛӘР

Кызыл Армиябезнең һәрбер фронтта алга баруы, һәр көн яңадан-яңа шәһәрләрне, халык яши торган бик күп пунктларны фашистлар кулыннан азат итүе «Новая гора» колхозы членнары арасында иксез-чиксез шатлык тудырды.

Шушы уңай белән без фронтка ярдәм итүне тагын да көчәйттек. Без дәүләткә 1942 нче ел өчен ашлык, ит һәм башка продуктлар тапшыруны күптән тәгәлләдек. Күптән түгел үзебезнең гомуми җыелышыбызда фронтка ярдәмне тагын да көчәйтү мәсьәләсен тикшердек. Кызыл Армия фондына колхозның гомуми фондыннан тагын 60 центнер ашлык бирү турында карар кабул иттек. Хәзер без шул ашлыкны ашлык тапшыру пунктына чыгарабыз.

Мин Кызыл Армия фондына үз хуҗалыгымдан 1 центнер ашлык һәм 1 сарык бирдем. Башка колхозчылар да бу эшкә актив катнашалар. Мәсәлән, иптәш А. С. Соловьева Кызыл Армия фондына 32 килограмм борчак, 32 килограмм ашлык, иптәш А. Миронов 16 килограмм борчак, бер тавык, иптәш П. И. Соловьев 1 сарык, А. Осокин, Ф. Соловьева, М. Лопатина иптәшләр 32 шәр килограмм ашлык, З. Лукиянов, О. Соловьев, М. Соловьева, П. Соловьев иптәшләр 16 шар килограмм ашлык бирделәр.

М. И. СОЛОВЬЕВ,
Чепья районы, «Новая гора» колхозы председателе.

Тагын да яхшырак эшләрбез

АЗНАКАЙ, 8 март. (Телефон буенча). Куйбышев исемендәге колхоз членнарының бүгенге митингысы күтәренке рух белән үтте. Иптәш Сталинга Советлар Союзы Маршалы исеме бирү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указын колхозчылар зур-күтәренкелек белән каршы алдылар. Колхоз председателе иптәш Кашапова колхозчыларның уртак теләкләрен чагылдырып болай диде:

— Даһи юлбашчыбыз иптәш Сталин безне һәрвакытта да җиңүләрдән җиңүләргә алып барды һәм алып бара. Безнең бөтен ышанычыбыз һәм киләчәгебез аңарга багышланган. Ул безнең атабыз. Аның җитәкчелегендә без җиңүгә ирештек һәм ирешербез. Дошманны, һичшиксез, тар-мар итәрбез. Иптәш Сталинга Советлар Союзы Маршалы исеме бирү турындагы хәбәр безне тагын да рухландырды.

СТАХАНОВЧЫ ВАХТА

Кызыл Армиянең 25 еллыгы көннәрендә Н-че заводның ремонт-механика мастерское стахановчы вахтага баскан иде. Ул вакытта алган йөкләмәләрен намус белән үтәгән металлистлар бөек 1 нче Май бәйрәмен лаеклы каршылау өчен ярышка чыгарга булдылар.

Производство алдынгыларының саны көннән-көн арта. Токарь цехында мастер Щегалев сменасы уңышлы эшли. Иптәш Сунцов җитәкчелегендәге токарьлар бригадасы заданиене 189 процентка үти. Иптәш Черников бригадасының членнары сменасына норма ярымшар эшлиләр.

ВЛКСМ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

Дөбъяз районы һәм комсомол оешмасы секретаре иптәш Зескина булган завод һәм 6 нче номерлы ФЗӨ мәктәбе комсомол оешмаларының азат ителгән өлкәләргә авыл хуҗалыгы продуктлары, йорт кирәк-яраклары, киемнәр, аяк киемнәре белән, шулай ук транспортны һәм промышленностьны аякка бастыру өчен кирәк булган җиһазлар белән җәмәгатьчелек ярдәме оештыру турындагы инициативаларын ВЛКСМ Өлкә Комитеты яхшы дип тапты.

Комсомолның шәһәр һәм район комитетларына азат ителгән өлкәләргә ярдәм оештыру буенча комсомолецлар арасында масса-аңлату эшләрен киң җәелдерергә, бу мәсьәләне комсомол җыелышларында тикшерергә кушты.

ВЛКСМ Өлкә Комитетының пропаганда һәм агитация бүлегенә азат ителгән өлкәләр һәм районнар өчен китаплар, әдәбият, музыка инструментлары җыюны оештырырга кушылды.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты комсомол комитетларына азат ителгән район балалары өчен җиңел һәм җирле промышленность предприятиеләрендә һәм промкооперациядә производство калдыкларыннан әйберләр эшләүне оештырырга, уку әсбаплары һәм башка төрле мәктәп җиһазларын җыярга тәкъдим итте.

ХАЛЫКАРА КОММУНИСТИК ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНАЛЫ УТЫРЫШ

Кичә Татар Дәүләт Академия театрында Казан шәһәрендәге партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмаларының, халыкара коммунистик хатын-кызлар көненә багышланган тантаналы утырышы булды. Доклад белән ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Измайлова чыкты. Ул ватан сугышында хатын-кызларның гаять зур роль уйнавы турында, Татарстан хатын-кызларының патриотик эшләре турында сөйләде.

Залга Казан гарнизонының хәрби частьларыннан делегация килеп керә. Гарнизон сугышчылары һәм командирлары исеменнән иптәш Куницын Татарстан хезмәт иясе хатын-кызларны котлый.

Верховный Баш Командующий Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинга, зур күтәренкелек белән котлау хаты кабул ителә.

Тантаналы утырыштан соң зур концерт булды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

7 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

7 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Гжатскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер төн эчендә совет частьлары халык яши торган 20 пунктны алдылар. Халык яши торган бер зур пункт өчен булган сугышта 400 гә якын гитлерчы кырып ташланды, 8 танк, 5 орудие, күп кенә пулеметлар, винтовкалар һәм патроннар кулга төшерелде. Гжатск өчен булган сугышларда безнең частьлар шәһәргә килү юлларында 1.200 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Гжатск шәһәренең үзендә бер полктан артык пехотадан торган немец гарнизоны кырып ташланды.

* * *

Оленино-Чертолинодан көньяктарак безнең гаскәрләр халык яши торган дистәләрчә пунктларны азат иттеләр. Совет частьларының ударлары астында чигенгән чакта немецлар коралларын һәм техникаларын ташлап калдыралар. Халык яши торган бер пункт районында гына да безнең гаскәрләр 9 танк, 10 автомашина, 40.000 патрон һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Трофейларның саны алына.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак совет подразделениеләре бер төн эчендә 200 гә якын гитлерчыны кырдылар. Трофейлар кулга төшерелде. Немецларның 336 нчы һәм 294 нче пехота дивизияләреннән пленныйлар алынды. Плен алынучыларның әйтүләренә караганда, бу районда немец гаскәрләре, бигрәк тә артиллерия һәм миномет утыннан, зур югалтуларга дучар ителәләр.

Совет зенитчиклары немецларның 3 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Харьковтан төньяк-көнбатыштарак безнең частьлар, бик каты сугышлар нәтиҗәсендә, халык яши торган ике пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның 300 гә якын үле гәүдәләре һәм яндырылган 8 танкысы калды. Безнең сугышчылар 5 орудие һәм 28 миномет кулга төшерделәр.

* * *

Дмитриев-Льговскийдан көнбатыштарак безнең частьлар кулга төшерелгән районнарны дошманнан чистарттылар һәм халык яши торган пунктларда чолганып алынган немец гарнизоннарын кырып бетерделәр. Ике көн эчендә 24 орудие, 26 миномет, 200 пулемет, 2 склад һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта иптәш Крюков командалыгындагы частьның сугышчылары 22 орудие, 100.000 патрон, 90 ат кулга төшерделәр. Безнең подразделениеләр тарафыннан чолганып алынган халык яши торган бер пунктта немецларның бер ротасы корал ташлады һәм пленга бирелде.

* * *

Төньяк-Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть халык яши торган бер пунктка бәреп керде һәм аны алды. Дошманның контратакалары аның өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. Немецларның бер ротага якын пехотасы юк ителде һәм 6 танкысы сафтан чыгарылды.

Безнең очучылар һава сугышларында дошманның 16 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Курск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның бер группа партизаннары февраль урталарында тимер юлны шартлатканнар. Дошманның бу юлдан килә торган бер бронепоезды һәлакәткә очраган. Курск партизаннарының икенче бер отряды немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз һәм 14 вагон җимерелгән.

* * *

Түбәндә Ленинград өлкәсенең Добросли авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Ел ярым эчендә ерткыч фрицлардан без бик күп хәсрәт һәм кимсетүләр күрдек. Гитлерчылар авылга бәреп керү белән үк, йозакларны ватып, крестьяннарны талый башладылар. Немецлар, ату һәм асу белән куркытып, безнең кызларыбызны һәм улларыбызны Германиягә каторгага куып алып киттеләр. Хәзер авылда бер кыз да, бер егет тә юк. Фашист ерткычлар Иван Александров дигән картны, колхозчы Фекла Дмитриеваны һәм башка кешеләрне үтерделәр. Көнбатышка таба чигенгән чакта немецлар авылны яндырдылар. Доброслины алган кызылармеецлар ярдәме белән генә без янгынны сүндереп, йортларны коткарып кала алдык. Кызыл Армия сугышчыларына һәм командирларына чын күңелдән рәхмәт әйтәбез. Ватаныбызны немец пычракларыннан тулысынча чистартуда Кызыл Армиягә ярдәм итү өчен бөтен көчебезне бирербез». Актка К. Семенова, Т. Васильева, М. Иванова, Д. Васильева, Е. Ковалева, П. Иванова һәм башкалар кул куйган.

батальонга якын пехотасы кырып ташланды.

* * *

Севскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары, алга таба барып, халык яши торган берничә пунктны алдылар һәм 2 орудие, 14 пулемет, 5 миномет һәм бер кием складын кулга төшерделәр. Н-че берләшмә частьлары сугышларның өч көне эчендә 1.000 нән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Шул ук вакыт эчендә 29 орудие, шулардан 4 самоход орудие һәм 2 сугыш припаслары склады кулга төшерелде.

* * *

Төньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, атака нәтиҗәсендә, көчле итеп ныгытылган халык яши торган бер пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре һәм немецлар ташлап калдырган бик күп кораллар калды.

* * *

Чернигов өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары кинәт немец алпавытының имениесенә бәреп кергәннәр. Куркуга төшкән сакчылар качып киткәннәр. Халык өчен үч алучылар, гитлерчылар тарафыннан крестьяннардан талап алынган ашлык тутырылган элеваторны яндырганнар һәм терлекләрне куып алып киткәннәр. Шул ук отрядның бер группа партизаннары тимер юл магистраленең бер участогына миналар куйганнар. Немецларның сугыш припаслары төялгән бер эшелоны миналарга бәрелеп шартлаган һәм тимер юлдан авып төшкән. Шуның өстенә совет патриотлары соңгы көннәрдә дошманның 3 паровозын һәм сугыш милекләре төялгән 40 вагонын юк иткәннәр.

* * *

Харьков өлкәсенең Мерефа шәһәреннән чигенер алдыннан немец-фашист кабахәтләр гражданнар халкын кан коеп җәзалаганнар. Ржавский урамында гына да фашист башкисәрләр 11 кешене атып үтергәннәр. Киевский һәм Ново-Проезжий урамнарында гитлерчылар беренче очраган кешеләрне—Иван Писаренконы, Карп Сергеенконы һәм башкаларны атканнар. Шәһәрдән чигенгән чакта фашист ерткычлар күп кварталларны һәм урамнарны яндырганнар. Бандитлар квартираларга бәреп кергәннәр, әйберләргә сыек ягулык сипкәннәр һәм йортларга ут төрткәннәр.

* * *

Бер группа Бельгия патриотлары Льеж якынындагы бер хәрби заводка үтеп кергәннәр һәм бик күп кул пулеметларын кулга төшергәннәр. Мехельн шәһәре районында кораллы бельгиялеләр отряды 11 немец мотоциклчысын юк иткән. Нивель шәһәреннән ерак түгел генә Бельгия патриотлары немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар.

7 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

7 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның 6.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

28 нче февральдән 6 нчы мартка кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм аэродромнарда немецларның 129 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 76 самолет югалттык.

* * *

6 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Гжатскидан көнбатыштарак һәм төньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Безнең частьлар халык яши торган 74 пунктны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Оленино-Чертолинодан көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Совет сугышчылары дошманны авыр югалтуларга дучар итәләр һәм, аны бертуктаусыз куып барып, яңа оборона чикләренә ныгып урнашырга мөмкинлек бирмиләр. Бер көн эчендә безнең частьлар халык яши торган 20 дән артык пунктны немец-фашист басып алучылардан азат иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде.

Зенит артиллериясе уты белән немецларның 8 самолеты атып төшерелде.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары, тоткарлыкларны һәм көчле ут каршылыгын җиңеп, дошманның окопларына бәреп керделәр. Немецларның 200 гә якын солдатлары һәм офицерлары, 4 минометы, 18 пулеметы юк ителде. 2 ДЗОТ ы һәм 13 блиндажы җимертелде. Разведчик-саперлардан Журавлев һәм Романович иптәшләр, дошман тылына барып чыгып, берничә урыннан тимер юлны шартлаттылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че артиллерия часте, пехота белән бергә хәрәкәт итеп, соңгы сугышларда немецларның 14 танкысын, 8 бронемашинасын һәм сугыш йөкләре төялгән 25 автомашинасын юк итте. Дошманның бер

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Төньяк-Көнбатыш фронт). Рәсемдә: өлкән лейтенант А. Хужин командалыгындагы чаңгычы - автоматчикларның штурм группасы сугыш заданиесен үтәргә бара.

ТАСС фотохроникасы.

8 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

8 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Гжатскидан көнбатыштарак һәм төньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта ике ротага якын немец пехотасын кырып ташлады. 5 орудие, 17 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр дошманның тылына барып чыктылар. Чолганып алынудан куркып, гитлерчылар тәртипсез рәвештә чигенделәр.

* * *

Оленинодан көньяктарак безнең частьлар, бик каты сугышлар нәтиҗәсендә, дошманның көчле итеп ныгытылган каршылык күрсәтә торган 6 узелын алдылар. 7 орудие, 13 миномет, 26 пулемет һәм 600 дән артык гитлерчы юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең частьлар дошманга каршы артиллерия һәм миномет уты алып бардылар. Безнең артиллериябез уты белән дошманның 10 ДЗОТ ы һәм блиндажы җимертелде, 4 орудиесе сафтан чыгарылды һәм җыелып тора торган пехотасы таркатылды. Дошман окопларына бәреп кергән Н-че часть сугышчылары, үзләренең югалткан позицияләрен кайтарып алырга маташкан гитлерчыларның контратакасын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә 100 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде.

Һава сугышларында һәм зенит артиллериясе уты белән немецларның 5 самолеты атып төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар дошманның бик күп танкларына һәм мотопехотасына каршы сугышлар алып бардылар. Бер участокта немецлар сугышка, 60 танк ярдәме белән, мотопехота керттеләр. Совет сугышчылары бер батальонга якын немецларны юк иттеләр, дошманның 12 танкысын яндырдылар һәм зарарладылар, нәтиҗәдә дошман үзенең элекке позицияләренә чигенергә мәҗбүр ителде.

* * *

Севскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Каршылык күрсәткән аерым немец гарнизоннары кырып ташланды. Бер участокта дошман контратака ясаган иде. Совет сугышчылары дошманны алып ташладылар һәм, аны куып барып, халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның 300 гә якын үле гәүдәләре калды. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Гомель өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары февраль аенда немецларның 8 полиция участогын туздырганнар. Дошманга каршы сугышларда һәм засадалардан торып 100 дән артык гитлерчы кырып ташланган. Совет патриотлары 2 пулемет, 80 винтовка һәм күп кенә патроннар кулга төшергәннәр. Шул ук вакыт эчендә партизаннар немецларның 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. 2 паровоз һәм 20 вагон җимерелгән.

* * *

7 нче пехота дивизиясенең 19 нчы полкыннан Кызыл Армия ягына чыккан солдат Герберт Н. болай диде: «Сталинград янында немецларның 6 нчы армиясенең юк ителүе уңае белән Германиядә өч көнлек кайгы игълан ителү турындагы хәбәр безне бөтенләй аптырашта калдырды. Соңгы вакытларда солдатлар сугышның нәтиҗәсе турында бик күп сүзләр сөйләшәләр. Күптән түгел бер обер-ефрейтор болай диде: «Өч көнлек кайгы—ул әле эшнең башы гына. Алда әле күп кайгылы көннәр һәм айлар тора. Госпитальләрдән кайтучы солдатларның әйтүенчә, Германиядә армиядә хезмәт итәргә яраклы ирләр барысы да инде алынганнар. Зенит частьларында һәм һава һөҗүменнән саклану гаскәрләрендә хезмәт итүче солдатлар пехотачылар сыйфатында фронтка җибәрелгәннәр. Алар урынына гаскәри хезмәткә яраклы булмаган инвалидлар куелган».

* * *

Курск өлкәсенең азат ителгән Логовое авылы кешеләре немец-фашист кабахәтләрнең коточкыч ерткычлыклары турында сөйләделәр. Авылда үтерелгән 2 немецның гәүдәсе табылган булган. Гитлерчылар, 88 кешене каберлеккә куып алып барып, үтерүдә кемнәр катнашканлыкны белү өчен аларны озак газаплаганнар. Газаплауларга да карамастан, алар бернәрсә дә белә алмаганнар. Шуннан соң фашист палачлар мелькомбинат эшчесе Кузьма Унковскийны, грузчик Иван Купинны, комбайнчы Максим Нероновны, колхозчылардан Александр Подставкинны, Василий Сопатовны, Иван Демьяновны һәм башкаларны, барлыгы 20 кешене атып үтергәннәр.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

ОРЛЫК — ЯЗГЫ ЧӘЧҮНЕҢ АЛТЫН ФОНДЫ

Орлык туплау, тазарту һәм аларның тишелеп чыгышын тикшереп чыгу эшен большевикларча оештырыйк, быел язгы чәчүнең тик югары сыйфатлы орлык белән генә үткәрелүенә ирешик!

„... „Яңа ил" колхозының мөрәҗәгатен колхозчылар арасында, МТС һәм колхоз эшчеләре арасында киң күләмдә тикшерергә, һәрбер колхоз, МТС һәм совхоз буенча СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының шушы ел 27 нче февраль карары нигезендә, шулай ук ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарлары нигезендә конкрет чаралар билгеләргә һәм чәчүгә үрнәк булырлык тестә әзерләнүне тәэмин итәргә..."

(Фронт айлыгы үткәрү турыда ТАССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты карарыннан).

Айлыкның 5 нче көне

Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы игълан ителүгә бүген 5 нче көн бара. «Кызыл Татарстан» редакциясенә авыллардан килә торган хәбәрләр, колхозчыларның бу айлыкны алкышлап каршы алганлыкларын, чәчүгә үрнәк булырлык итеп әзерләнү өчен җиң сызганып эшкә керешкәнлекләрен күрсәтәләр.

Менә Лаеш районының «Яшәсен иркенлек» колхозы тимерчеләре Салихов һәм Нигъмәтуллин иптәшләр. Алар айлык игълан ителгән көнне үк яңа йөкләмәләр алдылар һәм, элеккегә караганда берничә тапкыр кызурак темп белән эшкә керешеп, машиналарга ремонт ясауны тәмамладылар. Чепья районының «Кызыл юл» колхозы членнары да язгы чәчүгә әзерлек эшен барлык тармаклар буенча күп тапкыр көчәйттеләр һәм бик яхшы беренче нәтиҗәләргә ирештеләр дә инде. Алар колхозны барлык культуралар буенча да чәчү орлыклары белән тулысынча тәэмин иттеләр.

Фронт айлыгы башлану уңае белән күп кенә колхозларның членнары бик гүзәл яңа инициатива күрсәтәләр: үз колхозларына бурычка чәчү орлыклары биреп торалар. Шөгер районының Ормышлы авыл советына караган «Техника», «Кызыл юл» һәм «Авангард» колхозларында бу эш бигрәк тә җәелеп килә. Дөбьяз районында да бу өлкәдә яхшы гына нәтиҗәләр бар. Бу—бик табигый. Чөнки орлык ул, язгы чәчүнең алтын фонды. Һәрьяктан яхшы сыйфатлы орлык әзер түгел икән, язгы чәчүнең уңышлы үтәчәге турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Алдынгылардан үрнәк алырга, колхозларны чәчү орлыклары белән тизрәк тәэмин итү өчен җирле мөмкинлекләрдән киң күләмдә файдалануны оештырырга кирәк. Фронт айлыгы, чыннан да, республикабызда язгы чәчүгә үрнәк булырлык әзерлекне тәэмин итәргә тиеш.

Ләкин, кызганычка каршы, кайбер районнарда фронт айлыгы буенча алга куелган бурычларның әһәмиятенә тиешенчә бәя биреп җиткермәү фактлары бар. Мисал өчен Кызыл юл районын алырга була. Айлыкның бер атнасы инде үтеп баруга да карамастан, бу район җитәкчеләре (ВКП(б) ның район комитеты секретары иптәш Хәйретдинов) һаман да әле айлык турында бушка сөйләнеп йөрүдән ерак китә алганнары юк. Бу районның кайбер колхозларында айлыкны үткәрү буенча эшкә керешү түгел, хәтта аның игълан ителүен дә белмиләр. Язгы чәчүгә әзерлек мәсьәләләрендә мондый борыла алмаучанлык һич тә гафу ителмәслек хәл булып тора. Айлыкны оештырырга, аңар кичекмәстән һәрбер колхозның һәм һәрбер совхозның, МТС һәм МТМ ның катнашуына ирешергә кирәк. Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы чыннан да фронттагыча җитез үтәлергә, һәм уңышлы нәтиҗәләр белән тәмамланырга тиеш.

Бәрәңге чәчү мәйданын киңәйтү өчен

Бәрәңге—иң әһәмиятле культураларның берсе. Ул һәр гектардан туклылык әйберләрне башка күп кенә культураларга чагыштырганда ике-өч тапкыр артыграк бирә. Бәрәңге—ул, спирт һәм крахмал-патока промышленносте өчен чимал бирүче төп культура. Шуңа күрә хәзер, бигрәк тә сугыш вакытында, бәрәңге чәчү мәйданын киңәйтү буенча барлык чаралардан тулысына файдаланырга кирәк.

Азыкка дип билгеләнгән бәрәңгеләрнең күзәнәкләре күп булган очларын кисеп, кисенте орлык әзерләү бәрәңге чәчү мәйданын киңәйтүдә бик яхшы чара булып тора. Үткән елгы тәҗрибәләр моны бик ачык күрсәтте. Күп кенә колхозлар бәрәңге чәчү буенча дәүләт тарафыннан бирелгән заданиене тулысынча үтәү өстенә кисентеләр чәчеп, өстәмә бик күп продукцияләр алдылар. Быел бу методны тагын да киңрәк кулланырга кирәк.

Ләкин үткән елны кайбер урыннарда кисенте әзерләүдә һәм аларны саклауда кимчелекләр дә булды. Быел ул кимчелекләр һич тә кабатланмаска тиеш.

Барыннан да элек, кисентене дөрес итеп, игълы бәрәңгенең күзәнәкле башыннан кисеп алырга кирәк. Һәрбер кисентенең авырлыгы 10—15 грамм, ә аеручә эре бәрәңгеләрдән кисеп алынганнарының авырлыгы 20 граммга кадәр булырга тиеш.

Кисенте әзерләү өчен ауру, чери башлаган, яки суык тигән бәрәңгеләр ярамый.

Кисентеләрне бозмый саклау бигрәк тә җаваплы. Аларны кисеп алгач та 6—8 көн буена бәрәңге саклау урыннарында җиңелчә киптерергә, моның өчен аларны юка катлау итеп (2—3 кисенте биеклегендә) таратып салырга кирәк. Ә аерым хуҗалык шартларында исә кисентеләрне торак йортта, бүлмә температурсында бер-ике көн киптерү җитә. Шуннан соң кисентеләрне 20—25 һәм 40 сантиметрга кадәр калынлыкта өеп куярга мөмкин. Саклау урынында җылылык 1—3 градус булырга итеш. Саклауга салынган кисентеләр череп бозыла башласалар, черекләрне кичекмәстән җыеп алырга һәм кисентеләргә коры ком сибәргә кирәк.

Казан селекция станциясе үткән елны бу өлкәдә күп кенә сынаулар үткәрде. Аның комга аралаштырып саклаган кисентеләренең бары бер проценты гына бозылды. Станция бу орлыкны яровойлаштырып утыртты һәм һәр гектардан уртача 1.315 пот уңыш алды. Комга катнаштырып салу кисентеләрне черен бозылудан гына түгел, кибүдән дә саклый. Ә бу исә бик әһәмиятле.

Х. РӘМИЕВ,

Казан селекция станциясенең фәнни өлкән сотрудниты.

Тракторчылар йөкләмәсе

БАЛТАЧ. (Телефон буенча). Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның 23 нче февраль приказы Балтач МТС эшчеләре арасында хезмәт энтузиазмын бик нык күтәрде. Бу приказны өйрәнү өчен чакырылган митингта эшче һәм хезмәткәрләрнең бөтенесе дә катнашты һәм 16 кеше чыгып сөйләде. Алар барысы да үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алып, язгы чәчүне уңышлы итеп үткәрү буенча бер-берсен социалистик ярышка чакырыштылар.

МТС ның алдынгы тракторчысы Мәдинә иптәш Миңлемуллина үзенә беркетелгән тракторны ремонтлауны 15 нче мартка тәмамларга, язгы чәчү вакытында, йомшак җир сөрүгә күчереп исәпләгәндә, 1.100 гектар җир сөрергә, эшләп чыгаруның үзенә төшү бәясен 15 процентка киметергә, ягулыкка 15 процент экономия ясарга йөкләмә алды һәм үзе белән тиңләшергә тракторчы иптәш Рамазановны социалистик ярышка чакырды. Иптәш Рамазанов бу чакыруны кабул итте. Хәзер МТС ның барлык эшчеләре дә үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр.

Г. ГАЙНЕТДИНОВ.

Алдынгылардан калышмаска

БАЛЫК БИСТӘСЕ, 8 март. (Телефон буенча). «Ударник № 3» колхозы дәүләткә ашлык тапшыруны, 1942 нче ел өчен ит, сөт, йон, йомырка һәм башка продуктлар тапшыруны срогыннан алда үтәде.

Колхозчылар иптәш Сталинның 23 нче февраль приказы белән чиксез рухландылар. Алар хәзер ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарларын өйрәнәләр һәм 1943 нче елда югары уңыш алу өчен ныклап әзерләнәләр. Колхозда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тәмамланган. Чәчүлек орлык барлык культуралар буенча да җитәрлек. Орлыклар чистартылган, һәм алар коры урыннарга салып куелган. Орлыкларның тишелеп чыгышын тикшерү яхшы нәтиҗә бирде: алар һәр яктан кондицияле булып табылдылар. Кар тоту, көл, кош тизәге җыю планнары да үтәлгән. Хәзер кырга тирес чыгару бара. Атларның торышы яхшы.

Бу колхоз членнары язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгына бердәм кушылдылар һәм чәчүгә әзерлек буенча тагын да тырышыбрак эшли башладылар.

«Чулпан», «9 нчы январь», «Оборона страны» һәм Сталин исемендәге колхозларда да фронт айлыгы яхшы оештырылган, һәм ул уңышлы нәтиҗәләр бирә.

Шул ук вакытта районда язгы чәчүгә әзерлек буенча бик артта баручы колхозлар да юк түгел. Мәсәлән, «Герой труда», «Красная нива» һәм Степан Разин исемендәге колхозларда машиналарга ремонт ясау эшенә һаман да әле керешкәннәре юк. Орлык чистарту да тәмам булмаган. Кайбер культуралар буенча чәчү орлыклары җитәрлек түгел. Ә бу колхозларның җитәкчеләре орлыкның кайдандыр читтән килгәнен көтәләр, җирле мөмкинлекләрдән файдаланмыйлар.

ҮРНӘК АЛЫРЛЫК ЭШ

ШӨГЕР, 8 март. (Үз хәбәрчебездән телефон буенча). Ормышлы авыл советына караган «Техника» колхозы членнарының җыелышы булды. Колхозчылар ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарын бик яхшы дип таптылар һәм тулысынча үтәү, фронтка һәм илебезгә авыл хуҗалыгы продуктларын тагын да күбрәк җитештерү өчен армый-талмый эшләячәкләрен белдерделәр.

Язгы чәчүгә әзерлек һәм терлекчелек тармакларындагы җитешсезлекләр каты тәнкыйть астына алынды. Аларны бетерү өчен практик чаралар билгеләнде.

Колхозда чәчү орлыклары җитешеп бетми. Бу турыда сүз чыккач та, колхозның агротехнигы иптәш Саттаров:

— Без хәзер чәчү орлыгын кайдан да булса читтән көтеп тора алмыйбыз. Без бер буразна җиребезне дә буш калдырмаска тиешбез. Мин үз хуҗалыгымнан бер центнер бөртекле культура, бер центнер бәрәңге һәм яшелчә орлыклары бирәм.

Иптәш Саттаров тәкъдиме буенча колхозчылар:

— Безнең җиребезне башка колхоз чәчмәс. Без үзебезгә кирәкле барлык чәчү орлыкларын үзебездән табарга сүз бирәбез, дигән карарга килделәр һәм шунда ук бер-бер артлы үз хуҗалыкларыннан чәчү орлыклары тәкъдим итә башладылар. Ә. Фәсхетдинов, Т. Фәсхетдинова иптәшләр алтышар пот, Хәлимова 3 пот һәм Фәхретдинова 2 пот орлык бирергә булдылар. Колхозчыларның җыелышы таралганчы ук 55 пот бөртекле культуралар орлыгы, 60 пот бәрәңге җыелды.

Ормышлы авыл советындагы «Кызыл юл» һәм «Авангард» колхозларында да бу гүзәл инициативаның беренче нәтиҗәләре бар. Мәсәлән, «Авангард» колхозчылары кыска гына вакыт эчендә 22 пот, «Кызыл юл» колхозчылары 100 поттан артык чәчү орлыклары җыйдылар һәм колхозга бирделәр.

М. ХӘМИДУЛЛИН.

ФАБРИКА ЭКОНОМИЯ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ

Сугыш вакытында һәрбер предприятие үз резервларын көчәйтү өчен барлык мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланырга, һәрнәрсәдә — эш көченә һәм вакытына, материалларга, чималга, акчага ныклы экономия ясарга тиеш.

Безнең 14 нче номерлы фабрика коллективы сугыш чорында экономия режимы буенча шактый эшләр башкарды. Узган елның соңгы ике аенда фабрика дәүләткә планнан тыш миллион сумга якын файда бирде. Фабрика балансында тупланган маяның бу күрсәткече коллективның үз бурычын аңлавы һәм үтәве турында сөйли.

Фабрикада күп станокчылар хәрәкәте киң җәелдерелде. Шуның нәтиҗәсендә хезмәт җитештерүчәнлеге 37 процентка күтәрелде. Бу, эшчеләрнең саны бер килеш торуга карамастан, фабрикага производство планнарын ай саен арттырып үтәп барырга мөмкинлек бирә.

Чималга экономия ясау хәзер бигрәк тә әһәмиятле. Чөнки экономиядән алынган чималдан өстәмә продукция эшләп чыгарырга мөмкин. Фабрика отходларны 50 процентка киметергә дип алган йөкләмәсен уңышлы үтәп бара. Элек бракка чыгарылган отходлар хәзер яңадан карап чыгылып, сайланып алыналар һәм эшкә кертеләләр. Шулай эшләү нәтиҗәсендә бер январь аенда гына да отходлардан 1819,8 килограмм йон җеп производствога кире кайтарылды. Моның белән фабрика 25.000 сум файда алды.

Ноябрь, декабрь һәм январь айларында производствога кире кайтарылган отходлардан 10.000 сумлык төрле киң куллану товарлары җитештерелде. Без чималның һәм материалның бер генә граммы да, бер генә сантиметры да әрәм китмәсен өчен көрәшәбез һәм бу көрәш әнә шундый күңелле нәтиҗәләр бирә.

Электр энергиясе һәм ягулыкка экономия ясау өлкәсендә дә фабрика шактый уңышларга иреште. Ныклы экономия режимын тормышка ашыру нәтиҗәсендә электр энергиясе расходы планда күрсәтелгәнгә караганда 15 процентка кимеделде.

Ләкин ирешелгән уңышлар белән генә һич тә канәгатьләнергә ярамый әле. Фабрикада экономия чыганаклары күп. Аларны эзләп табарга һәм булган резервларны тулысынча хәрәкәткә китерергә кирәк. Ул вакытта без илебезгә тагын да күбрәк файда бирербез.

О. ВИЗЕМАН,

14 нче номерлы фабрика директоры.

БӘРӘҢГЕ КИСЕНТЕЛӘРЕ ӘЗЕРЛӘҮ

Столбище районы колхозларында орлыкка бәрәңге кисентеләре әзерләү киң җәелдерелде. «Спартак» колхозы (председателе иптәш Косов) кисентеләр әзерләү буенча район җир бүлегеннән бирелгән планны тулысынча үтәде һәм хәзер планнан тыш әзерләү бара. Шулай ук Ленин исемендәге колхозда да 19 центнер кисенте әзерләделәр инде. «Дружба» колхозында да план үтәлеп килә.

Бу колхозларда кисентеләрне саклау эшенә җитди игътибар бирелә. Кисентеләрнең бозылу факты юк.

И. КОНДРАТЬЕВ.

НАГОРНЫЙЧЫЛАР КУРСЫ

Җир сөрүдә нагорныйчылар методын өйрәнү өчен Тәкәнеш районы үзәгендә махсус курс оештырылды. Курста 40 кеше укый.

Ф. ХӘМЗИН.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

Иске Пукпинер авылы, «Авангард» колхозы (Чепья районы) членнары колхозның гомуми фондыннан Кызыл Армия фондына 50 центнер ашлык тапшырырга карар бирделәр.

Г. ГАЛИАКБЕРОВ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

8 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

8 нче мартта безнең гаскәрләр, ике көн дәвам иткән каты сугышлардан соң, Сычевка шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар (Вязьма шәһәреннән төньяктарак).

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

7 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 20 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар, бер тимер юл эшелонын җимерделәр.

* * *

Безнең гаскәрләр дошманның бик каты каршылык күрсәтүен бастырып, каты сугышлардан соң Сычевка шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар (Вязьма шәһәреннән төньяктарак).

Гжатскидан көнбатыштарак безнең частьлар сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган 11 пунктны алдылар.

* * *

Оленинодан көньяктарак безнең гаскәрләр алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть участогында немецлар берничә тапкыр контратака ясап караганнар иде, ләкин совет сугышчылары аларны җимерделәр һәм алып ташладылар. Сугыш нәтиҗәсендә 600 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. 2 орудие, 22 пулемет, күп кенә винтовкалар, автоматлар һәм сугыш припаслары кулга төшерелде.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Совет артиллеристлары немецларның 20 дән артык ДЗОТ ларын һәм блиндажларын җимерделәр, 10 артиллерия һәм 8 миномет батареясының утын бастырдылар, дошманның 12 автомашинасын һәм бер самолетын юк иттеләр.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак немецларның ике батальонга якын пехотасы халык яши торган бер пунктны алырга маташып карады. Гвардияче өлкән лейтенант Якубов командалыгындагы безнең подразделениеләр дошманга каршы омтылышлы контратака ясадылар. Сан ягыннан өстен булса да, дошман штык ударына каршы тора алмады һәм ашыгыч рәвештә чигенде. Безнең сугышчылар 180 немец солдатын һәм офицерын юк иттеләр, 12 пулемет һәм 100 дән артык винтовка кулга төшерделәр.

* * *

Севскидан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып бардылар. Халык яши торган бер пунктта безнең сугышчылар дошман гарнизонын чолгап алдылар. Корал ташлаудан баш тарткан гитлерчылар юк ителделәр. Дошманның 250 солдаты һәм офицеры плен алынды. Шактый күп трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Төньяк-көнбатыш фронтта Н-че гвардия берләшмәсе частьлары дошманның көчле итеп ныгытылган позицияләрен алдылар. Бик каты сугышта бер батальонга якын немец пехотасы юк ителде. Безнең сугышчылар трофейлар кулга төшерделәр. Шулар арасында 10 танк һәм 12 орудие бар.

Совет очучылары һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 30 самолетын юк иттеләр. Шуның өстенә безнең зенит артиллериясе уты белән дошманның 11 самолеты атып төшерелде.

* * *

Калинин өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды халык яши торган бер зур пунктта немецлар гарнизонына һөҗүм иткән. Партизаннар немецларны үтергәннәр һәм бу пунктны алганнар. Кичкә таба немецлар партизаннарга каршы ике рота пехота җибәргәннәр. Партизаннар дошманның контратакасын кире кайтарганнар һәм 100 дән артык гитлерчыны кырып ташлаганнар. Калинин өлкәсе партизаннарының икенче бер отряды тимер юлга миналар куйган. Немецларның фронт линиясенә бара торган бер бронепоезды миналарга бәрелеп шартлаган. Паровоз һәм берничә бронеплощадка җимерелгән.

* * *

Курск өлкәсенең Малоархангельск районында немец-фашист кабахәтләр меңнән артык кешене атканнар һәм асканнар. Оккупация чорында фашистлар Малоархангельск шәһәреннән һәм тирә-як авыллардан 2.400 кешене ирексезләп Германиягә каторгага куып алып киткәннәр. Шәһәрдән чигенер алдыннан гитлерчы бандитлар ике урта мәктәпне, педагогия училищесын, кино - театрны, район көтепханәсен, больницаны, балалар йортын, балалар консультациясен һәм башка күп биналарны һәм торак йортларны яндырганнар.

* * *

Чех-Словакиянең Пильзен районында чех патриотлары совет-немец фронтына җибәрү өчен әзерләп куелган кораллар тутырылган складны шартлатканнар. Брно шәһәрендә бер группа кораллы чехлар немецлар гаражына һөҗүм итеп, 18 гитлерчыны үтергәннәр һәм 15 автомашинаны яндырганнар. Прага якынында чех патриотлары бер немец часте штабына бомба ташлаганнар. Шартлаудан зур җимерелүләр булган. 20 дән артык гитлерчы үлгән һәм яраланган.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ. Рәсемдә: Роммель армиясеннән союзникларга пленга төшкән немец һәм итальян солдатларын Аламейн тимер юл станциясеннән озаталар.

Халыкара хатын-кызлар көне 8 нче мартны бәйрәм итү уңае белән СССР хатын-кызларына котлаулар

АНГЛИЯ

Британия эшчеләре, профсоюз членнары исеменнән, Британия тред-юнионнары конгрессының генеральный советы председателе Анна Лофлин халыкара хатын-кызлар көне—8 нче март бәйрәме уңае белән СССР хатын-кызларына котлау җибәрде. Анна Лофлин болай дип яза:

«Производствоны күтәрү өчен Англия заводларындагы хатын-кызларның үзләренең барлык көчләрен бирүләренә һәм фашизмга каршы сезнең Кызыл Армиягез бик яхшы һәм җиңүчән роль уйный торган гаять зур көрәштә иң күп булышлык күрсәтергә омтылуларына СССР дагы хатын-кыз иптәшләребезне ышандыра алабыз. Безнең илебезнең һәм Америка Кушма Штатларының кораллы көчләре, Сезнең илегезнең кораллы көчләре белән дус булып, Германия һәм Италия фашизмын җир йөзеннән себереп ташлаячак көн тизрәк килеп җитсен иде.

Гомуми дошманга каршы көрәштә СССР һәм Англия халыкларының якынлыгы үзара тагын да якынлнанрак аңлашуга һәм һәр ике ил хатын-кызларының тагын да көчлерәк дуслыгына китерер».

Моңа каршы җибәргән җавап телеграммасында ВЦСПС секретаре иптәш Николаева болай дип яза:

«Совет профсоюзларына берләшкән эшче һәм хезмәткәр хатын-кызлар исеменнән, сезгә дусларча котлавыгыз өчен рәхмәт әйтәм һәм Англиянең барлык эшче хатын-кызларына безнең чын күңелдән булган сәламебезне һәм халыкара хатын-кызлар көне уңае белән котлавыбызны тапшыруыгызны үтенәм.

Быел Советлар Союзы хатын-кызлары халыкара хатын-кызлар көнен Гитлер Германиясенә һәм аның ялчыларына каршы ватан сугышының хәлиткеч моментында каршылыйлар. Совет хатын-кызлары 8 нче март көнен немец-фашист басып алучыларны тар-мар итү өчен, явыз дошманны тәмам җиңү өчен үзләренең көчләрен тагын да туплау билгесе астында үткәрерләр.

Англия хатын-кызларының халыкара хатын-кызлар көнен сугышчан төстә каршылаячакларына һәм үткәрәчәкләренә, Гитлер Германиясенә һәм аның ялчыларына каршы актив көрәш өчен үз сафларын тагын да тыгызрак туплаячакларына ышанычь белдерәм».

АКШ

НЬЮ-ЙОРК, 7 март (ТАСС). АКШ ның хәрби информация бюросы совет хатын-кызларына тапшыру өчен Американың хатын-кыз җәмәгать эшлеклеләреннән бик күп санда котлаулар алды.

АКШ президентының хатыны Элеонора Рузвельт үзенең котлавында болай дип яза: «Америка хатын-кызлары, Советлар Союзының хатын-кызларына булышлык күрсәтеп, барлык хәрби чараларда катнаштылар. Алар җиңүгә ирешү өчен ярдәм итәргә генә түгел, бәлки бу җиңүне мөмкин кадәр тизрәк булдыру өчен нык карар бирделәр.

Сугыш беткәннән соң, төрле илләрнең хатын-кызлары бу иҗади эштә катнашырга омтылырлар, һәм бу эшне барлык илләрдә дә тормышка ашырырга кирәк булыр. Мин, Америка хатын-кызларының шулай бергәләп эшләргә теләүләрен совет хатын-кызлары күрерләр, дип ышанам. Берләшкән милләтләрнең хатын-кызлары, әгәр дә алар бергәләп эшләсәләр, бөек эшләр башкара алачаклар».

АКШ ның хезмәт министры Перкинс ханым болай дип яза: «Берләшкән милләтләрнең сугышчыларына кирәк булган кoралларны һәм башка материалларны җитештерүне арттыру өчен Америка хатын-кызлары хәрби заводларга торган саен күбрәк һәм күбрәк киләләр. Алар Россия һәм башка барлык илләрнең хатын-кызлары белән бер сафта барып, көчәр державаларына каршы көрәшү өчен корал җитештерәләр. Америка хатын-кызлары Россия хатын-кызларын котлыйлар. Хәзерге вакытта АКШ та 16 миллионга якын хатын-кызлар эшлиләр. Ел ахырына кадәр юк дигәндә тагын 2 миллион кеше алар сафына басачак. Көчәр державаларына каршы көрәш алып баручы бөтен дөньяның хатын-кызлары ышана алалар—Америка хатын-кызлары җиңүне тәэмин итү өчен производствода актив катнашачаклар».

Америка армиясенең хатын-кызлардан төзелгән ярдәмче корпусының командиры полковник Оветта Хобби болай дип белдерә: «Совет хатын-кызларының батырлык һәм патриотизм эпопеясен сөйләп бирү һәм язып аңлату мөмкин түгел. Аларның гүзәл көрәшләрен Америка хатын-кызлары сокланып күзәтәләр. Рус хатын-кызларының көрәштә үтәгән рольләре белән Американың барлык хатын-кызлары мактаналар. Совет хатын-кызларының ару белмәүче тырышлыклары безнең өчен үрнәк булып тора». Производство профсоюзлары конгрессының хатын-кызлар бүлегеннән җибәрелгән котлавында болай диелә: «Хатын-кызларның киң күләмнәрдә хезмәткә тартылуы буенча сезнең илегезнең тәҗрибәсе, эшләүче хатыннарның балалары турында сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез, хатын-кызларга хезмәттә һәм хезмәт хакы алуда ирләр белән бер дәрәҗәдә мөмкинлек биргән сезнең тәртибегез,—болар барысы да безнең барыбыз өчен рухлану чыганагы булып тора».

Шулай ук Америка хәрби-диңгез флотының хатын-кызлардан төзелгән ярдәмче корпусының командиры лейтенант Макафидан, хезмәт министрлыгы, Гарвард университетының элекке профессоры Алиса Гамильтоннан, АКШ ның Норвегиядәге элекке илчесе Гарриман ханымнан, производство профсоюзлары конгрессы башкарма комитеты члены Элеонора Нельсоннан һәм башкалардан Советлар Союзы хатын-кызларына котлаулар алынды.

МЕДСЕСТРА

Рая Ибраһимова—орденлы хәрби фельдшер Нина Либманның өйрәнчеге. Ул аңардан күп нәрсәгә өйрәнде. Аның кул астында операцияләргә әзерләнү һәм үткәрү техникасын отлично үзләштерде.

Каты сугыш көннәрендә Рая операция ясау һәм яра бәйләү бүлмәләрендә тәүлекләр буе чыкмый эшләде. Бер вакыт немец-фашист бандитлары Кызыл Хач билгесе куелган йортны ерткычларча бомбага тоттылар. Операцион сестра бер генә минутка да эшен туктатмады. Ул яралы сугышчыларның тормышларын саклап калу өчен үзенең постында калды.

Хәрби бурычын үтәүдә үзен-үзен аямавы өчен татар халкының турылыклы кызы Рая Ибраһимова хөкүмәтебез тарафыннан Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

ШЕФТАГЫ ГОСПИТАЛЬДӘ

Арча районы, Казанбаш урта мәктәбе укучылары бер госпитальгә шефлык итәләр. Укучылар госпитальдә дәваланучы яралы сугышчылар арасында киң күләмдә культура-масса эшләре алып баралар. Алар Кызыл Армиянең 25 еллыгы көнендә дәваланучыларга бүләк итеп кисетлар, кульяулыклар, кәгазь, карандаш һәм 30 данә мендәр әзерләп китерделәр. Яхшы итеп әзерләнгән концерт бирделәр.

Р. САДЫЙКОВА.

10.000 СУМЛЫК ОТЫШ

Кукмарадагы «Кызыл тукучы» фабрикасы эшчесе Хәтимә иптәш Динмөхәммәтова икенче акчалата-әйберләтә түләнә торган лотерея билетына 10.000 сум акча отты. Шул ук фабрикада эшләүче иптәш Морозова алтын сәгать отты. с

Г. ГАЛИЕВ.

ФРОНТОВИК СЕМЬЯЛАРЫНА ЯРДӘМ КӨЧӘЯ

Киез итек-фетр фабрикасында фронтовикларның семьяларына ярдәм итү буенча төзелгән комиссия соңгы көннәрдә үзенең эшен шактый яхшыртты. Фронтвикларның семьяларына 400 пар киез итек бирелде. 20.000 сумнан артыграк акчалата ярдәм ителде. Соңгы көннәрдә тагын 1.000 пар киез һәм башка төрле аяк киемнәре әзерләнде.

Фабриканың балалар бакчасында һәм яслендә фронтовик балалары өчен 3 интернат группа оештырылды. Фабриканың профсоюз оешмасы фронтовик семьяларын яшелчә утырту өчен җир участоклары белән тәэмин итә

И. ТУКТАРОВ.

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1074 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 397